СОВЕТ ОРЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422629 д. Орел,
ул. Олимпийская, д.2а
тел: 4-49-10

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОРЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422629 Орел поселыгы,
Олимпия урамы, 2 а нчы йорт,
тел: 4-49-10

2020 елның 17 августы **136 номер**

КАРАР

«Орел авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 12 февралендәге 129 номерлы нигезләмәне раслау хакында» Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 61-ФЗ Федераль законнары нигезендә, 1997 елның 31-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында", 1998 ел 53-ФЗ номерлы "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында", 2003 елның 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" законнар белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы “Хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы карары, җирлек уставы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

1. «Орел авыл җирлеге территориясендә гражданнарга беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 12 февралендәге 129 номерлы Орел авыл җирлеге советы карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә- http://pravo.tatarstan.ru веб - адресы һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында- http://laishevo.tatarstan.ru веб–адресы буенча бастырып чыгарырга. Хәрби исәпкә алу башлыгының, белгечләрнең, хәрби исәпкә алу инспекторларының функциональ вазыйфаларын расларга
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык - Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Орел авыл җирлеге Советы рәисе **В.И.Фетилина**

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Орловка авыл җирлеге Советының
2020 елның 17 августындагы
136 номерлы карарына кушымта

«Орел авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында» 2020 елның 12 февралендәге 129 номерлы нигезләмәне раслау хакында» Лаеш муниципаль районының Орел авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү турында

1) 1) 3.8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
   3.8 хәрби комиссариатка ел саен 1 октябрьгә кадәр 15 яшькә җиткән ир-ат җенесендәге гражданнар һәм 16 яшькә җиткән ир-ат җенесе гражданнары исемлекләрен тапшырырга, Ә 1 ноябрьгә кадәр - киләсе елда хәрби исәпкә куелырга тиешле ир-ат җенесе гражданнарының хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән форма буенча исемлекләрен;
   (Абзац 2010 елның 1 апреленнән гамәлгә кертелгән 2010 елның 9 мартындагы 27-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә. - алдагы редакцияне карагыз.);

2) 2) 3.2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:
   3.2 хәрби комиссариатлар булмаган җирлекләрдә (шәһәр округларында), яшәү урыны яки тору урыны буенча гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алу (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча, альтернатив граждан хезмәте үтү урыны буенча теркәлүне расламаган җирлекләрдә (шәһәр округларында), Россия Федерациясе Оборона министрлыгы тарафыннан эшләнелә торган методик рекомендацияләр һәм Россия Федерациясе законнары, әлеге Нигезләмә нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Беренчел хәрби исәпкә алу торышы өчен әлеге органнар җитәкчеләре җавап бирә.
   (Пункт 2012 елның 10 апреленнән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 мартындагы 228 номерлы карары белән гамәлгә кертелгән редакциядә; 2020 елның 18 февраленнән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 6 февралендәге 103 номерлы карары белән гамәлгә кертелгән редакциядә - алдагы редакцияне карагыз.)